ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

27.08. 2025 Олы Кайбыч ав. № 151

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси мәгълүматларны эшкәртү сәясәте турында» 2020 елның 08 октябрендәге 203 номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси мәгълүматларны эшкәртү сәясәте турында» 2020 елның 08 октябрендәге 203 номерлы күрсәтмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.2 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) шәхси мәгълүматларга санкцияләнмәгән керү фактларын ачыклау һәм чаралар кабул итү, шул исәптән шәхси мәгълүматларның мәгълүмати системасына компьютер һөҗүмнәре нәтиҗәләрен ачыклау, кисәтү һәм бетерү һәм аларда компьютер инцидентларына җавап бирү буенча чаралар күрү;».

2. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров